
# Гайсина Суфия Касыймовна



Гайсина Суфия Касыйм кызы Сарман районы Нөркәй авылында туган. Урта мәктәпне Нөркәй авылында укыган, соңыннан Казан педагогия институтын тәмамлаган. Мөслим урта мәктәбендә (Мөслим лицеенда) рус теле һәм әдәбиятын укыта. Суфия Касымовна үз фәнендә иң көчле укытучылардан саналган: ул укыткан укучылар рус теле, рус әдәбияты буенча үткәрелгән олимпиадаларда призлы урыннар яулап килделәр. Аның кабинеты иң яхшы җиһазланган кабинетларның берсе була, стендлары гел яңартылып тора.

Суфия Касымовна РФССРның халык мәгарифе отличнигы, “Иң яхшы укытучы” Гранты иясе.